# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында" 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Элек кабул ителгән (чыгарылган) норматив хокукый актларга үзгәрешләр (өстәмәләр) кертә, аларның гамәлдә булуларын озайта, туктатып тора, юкка чыгара торган, үз көчләрен югалткан дип һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип таный торган муниципаль норматив хокукый актлар, мөстәкыйль теркәү номеры алып, муниципаль регистрга кертеләләр.";

2) 4 статьяда:

а) 1 өлешнең беренче абзацында "вазыйфаи затлар" сүзләрен "җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Өстәмә белешмәләр (муниципаль норматив хокукый актның яисә аның аерым нигезләмәләренең законнарга, муниципаль берәмлек уставына туры килүе (туры килмәве) турында вәкаләтле органның эксперт бәяләмәсеннән тыш) җирле үзидарә органнарына кергән саен вәкаләтле органга, җирле үзидарәнең вазыйфаи затларына җибәреләләр.";

в) 4 өлештә "белешмәләрнең" сүзеннән соң "(муниципаль норматив хокукый актның яисә аның аерым нигезләмәләренең законнарга, муниципаль

берәмлек уставына туры килүе (туры килмәве) турында вәкаләтле органның эксперт бәяләмәсендәге белешмәләрдән тыш)" сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ статья өстәргә:

"$4^1$ статья. **Муниципаль норматив хокукый актларга юридик экспертиза үткәрү**

1. Вәкаләтле орган муниципаль регистрны оештырганда һәм алып барганда:

муниципаль норматив хокукый актның Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук муниципаль берәмлек уставына туры килү-килмәвенә юридик экспертиза үткәрә. Юридик экспертиза муниципаль норматив хокукый акт вәкаләтле органга кергән көннән башлап кырык биш көннән дә соңга калмыйча үткәрелә. Кирәк булганда әлеге срок унбиш көннән дә артыграк булмаган вакытка озайтылырга мөмкин;

муниципаль норматив хокукый актның яисә аның аерым нигезләмәләренең законнарга, муниципаль берәмлек уставына туры килүе (туры килмәве) турында эксперт бәяләмәсе төзи һәм мондый бәяләмәне муниципаль регистрга кертә.

2. Муниципаль норматив хокукый актта Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына каршы килә торган нигезләмәләр ачыкланганда, вәкаләтле органның эксперт бәяләмәсе мондый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органына (җирле үзидарәнең вазыйфаи затына), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм прокуратура органнарына җибәрелә.";

4) 5 статьяда:

а) 1 өлешнең җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"өстәмә белешмәләр.";

б) 2 өлештә:

беренче абзацта "Өстәмә мәгълүматка" сүзләрен "Өстәмә белешмәләргә" сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта "вәкаләтле органнар" сүзләрен "дәүләт хакимияте органнары" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"муниципаль норматив хокукый актның яисә аның аерым нигезләмәләренең законнарга, муниципаль берәмлек уставына туры килүе (туры килмәве) турында вәкаләтле органның эксперт бәяләмәләре;

прокуратура органнарыннан кергән таләпләр, хатлар, башка мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, башка дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан кергән хатлар һәм бүтән мәгълүмат.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 13 декабре
№ 100-ТРЗ